ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**2023 елның 13 феврале** **Чистай шәһәре** **№ 76**

Гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз
яшәүче гражданга туры килә торган
керемнең максималь күләмен һәм
гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче
граждан милкендәге һәм 2023 елга
салым салынырга тиешле мөлкәт хакын
билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.3 статьясына таянып, “Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителергә тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы нигезендә, шулай ук «Татарстан Республикасының Бәяләүчеләр берлеге» Коммерциячел булмаган партнерлыгының 2023 елның 31 гыйнварындагы 18 нче хатына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану турында карар кабул итү өчен гражданнар кеременең максималь күләмен 2023 елга билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары милкендәге һәм гаиләнең һәр әгъзасына салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме - 316 980 сум.

2. Һәр гаилә әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме - 9211 сум.

3. Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип таныганда әлеге карарның 1.1 пунктчаларында һәм 2 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрдән файдаланырга.

4. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының торак сәясәте бүлегенә әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин

итәргә һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары П.Б. Емельяновка йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов